| | |
|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

| | |
|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 2016 ел, 19 сентябрь | № 656 |

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына министрның алты урынбасары булуны рөхсәт итәргә»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

4 бүлектә:

4.1.46 нчы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.46. Татарстан Республикасы халкының сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин ителеш нормативларын, шул исәптән аның составына керә торган муниципаль берәмлекләр өчен, шулай ук халыкның стационар булмаган сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин ителеш нормативларын исәпләү өчен төбәк коррекциясе коэффициентын билгели»;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.90 – 4.1.107 нче пунктчалар өстәргә:

«4.1.90. Федераль законнар, «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә сәнәгать сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итә.

4.1.91. Сәнәгать сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын әзерли.

4.1.92. Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгатьне үстерүгә булышлык күрсәткән чараларны тормышка ашыра.

4.1.93. Сәнәгать сәясәтен тормышка ашыру максатларында кабул ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшли һәм тормышка ашыруны тәэмин итә.

4.1.94. Татарстан Республикасында сәнәгать торышы мониторингын гамәлгә ашыра һәм кирәкле мәгълүматны соратып ала, Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының тотрыксыз үсеше куркынычларын кисәтү буенча чаралар күрә.

4.1.95. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллаштыру буенча тәкъдимнәр әзерли, Татарстан Республикасында сәнәгатьнең торышы һәм үсеше турында, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлекне стимуллаштыру чараларын тормышка ашыру хакында еллык доклад әзерләүне һәм бастырып чыгаруны тәэмин итә.

4.1.96. Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать кластерларын төзү һәм үстерү мәсьәләләре буенча сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

4.1.97. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм күрсәтү инфраструктурасы оешмалары белән берлектә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтүдә катнаша.

4.1.98. Аларга карата Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән сәнәгать өлкәсендәге стимуллаштыру чараларын куллану максатларында, индустриаль (сәнәгать) парклары, сәнәгать кластерлары, индустриаль (сәнәгать) паркларының идарә итүче компанияләре, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән өстәмә таләпләргә туры килүен раслый.

4.1.99. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына Татарстан Республикасы территориясендә булган хезмәт ресурслары турында һәм яңа эш урыннары булдыруда ихтыяҗлар хакында мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

4.1.100. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының төбәк һәм төбәкара хезмәттәшлеген үстерүдә, сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары һәм башка оешмалар арасында җитештерү һәм сәүдә элемтәләре булдыру юлы белән сәнәгать кооперациясен үстерүдә ярдәм күрсәтә.

4.1.101. Үз вәкаләтләре чикләрендә федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, халыкара оешмалар һәм чит ил дәүләтләренең административ-территориаль берәмлекләре белән сәнәгать сәясәте өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыра.

4.1.102. Үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы территориясендә оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең эшләве һәм аларны үстерү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә.

4.1.103. Федераль башкарма хакимият органнары белән Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәтен тормышка ашыру турында килешүләр әзерләүне гамәлгә ашыра һәм төзүне тәэмин итә.

4.1.104. Сәнәгать буенча дәүләт мәгълүмат системасы операторына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән составта һәм тәртиптә мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

4.1.105. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаган сәнәгать кластерлары, сәнәгать кластерларының махсуслаштырылган оешмалары реестрын алып баруны гамәлгә ашыра һәм әлеге реестрны алып бару тәртибен билгели.

4.1.106. Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнарының террорчылыкка каршы тору чараларын гамәлгә ашырганда, үзара хезмәттәшлеген көчәйтү максатларында, укулар үткәрүдә катнаша.

4.1.107. Үз компетенциясе чикләрендә экстремистлык эшчәнлеге һәм террорчылыкка каршы торуда катнаша, Министрлыкка беркетелгән объектларның террорчылыктан сакланышын тәэмин итә.»;

6 бүлектә:

6.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Министрлык боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә министр урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләүне гамәлгә ашыра.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков